Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен-Сәрдәсе авыл җирлеге

Керәшен-Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

«01» сентябрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставы, Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 74/15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына район халкының хокукларын үтәү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең Генераль планы (алга таба - текс буенча Генераль план) проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитетына (алга таба текст буенча - җирлек башкарма комитетына) йөкләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бөтен территориясендә (алга таба - Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге) торак пунктлар өлешендә - Керәшен Сәрдәсе, Иксуар һәм Колкомерка авыллары) уздырыла.

Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Керәшен Сәрдәсе авылында яшәүчеләр өчен: 2021 елның 4 октябрендә 10.00 сәгатьтә Керәшен Сәрдәсе мәдәният йорты фойесында (ТР, Питрәч районы, Керәшен Сәрдәсе авылы, Татарстан ур., 6а);

- Иксуар авылында яшәүчеләр өчен: 2021 елның 4 октябрендә 12.00 сәгатьтә Урман урамындагы 14 нче йорт янында;

- Көлкәмәр авылы халкы өчен: 2021 елның 4 октябрендә 14.00 сәгатьтә Мәктәп урамындагы 45 нче йорт янында.

4. Җирлек башкарма комитетына:

4.1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге мәгълүмат стендларында «Вперед» («Алга») район газетасында халык алдында тыңлаулар уздыру турында мәгълүмат бастырып чыгарырга.

4.2.Генераль план проектының эчтәлеге турында мәгълүматны Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге халкына җиткерү максатында Генераль план проектының демонстрацион материаллары күргәзмә-экспозициясен оештыру, җирле үзидарә органнары вәкилләре чыгышлары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында Генераль план проектын эшләүчеләрнең чыгышлары: 422786, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Керәшен Сәрдәсе авылы, Татарстан урамы, 6а йорт (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр (13-00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр төшке аш).

4.3. Әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән тәртиптә һәм срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4.4. Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында билгеләнгән тәртиптә бәяләмә әзерләргә һәм бастырып чыгарырга.

5. Генераль план проекты буенча гавами тыңлауларга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кызыксынучы затлар тарафыннан җирлек башкарма комитетына эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр, 13.00 сәгатьтән 17.001 сәгатькә кадәр, 2021 елның 1 октябренә кадәр (шул көнне кертеп), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, 422786, Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Керәшен Сәрдәсе авылы, Татарстан урамы, 6а йорт адресы буенча язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

6. Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегендә яшәүчеләр Интернет челтәрендәге генераль план проекты белән Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре - Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге» һәм территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында https://fgistp.economy.gov.ru таныша ала.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында таратырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы                    Н.В. Морозов